УДК 398

***И.Г. Закирова,***
***Г.Г. Гыйлемҗанова***

## ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ ДИНИ КОДЫ
### *(А.Х. Садыйкованың 80 яшьлек юбилее уңаеннан)*

В статье рассматривается научная деятельность доктора филологических наук Айслу Хусяиновны Садековой, внесшей значительный вклад в изучение татарского фольклора его взаимосвязи с исламской традицией. Особое внимание уделяется ее монографиям: «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» (1995), где проанализированы фольклорные элементы в творчестве писателя; «Идеология ислама и татарское народное творчество» (2001); «Ислам һәм татар халык иҗаты» (2005), а также фундаментальному труду «XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор» (2014). Отмечаются заслуги ученого как составителя сборников мунаджатов, редактора и переводчика изданий по татарскому религиозному фольклору.

**Ключевые слова:** Садекова Айслу Хусяиновна, Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова, татарское народное творчество, Г. Ибрагимов, духовная культура татар, мунаджаты

The article examines the scientific activity of Aisla Khusyainovna Sadekova PhD, who made a significant contribution to the study of Tatar folklore and its relationship with the Islamic tradition. Particular attention is paid to her monographs: “Folklore in the aesthetics of Galimdzhan Ibragimov” (1995), where folklore elements in the writer’s work are analyzed; “Ideology of Islam and Tatar folk art” (2001); “Islam həm Tatar halyk iҗaty” (2005), as well as the fundamental work “XII–XX Gasyr Bashy Tatar Adabiyatynda Dini Folklore” (2014). The merits of the scientist are noted as a compiler of collections of munajats, editor and translator of publications on Tatar religious folklore.

**Keywords:** Sadekova Ayslu Khusyainovna, Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, Tatar folk art, G. Ibragimov, spiritual culture of the Tatars, munajats

Олы галим, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре һәм гыйльми советы әгъзасы, Халыкара Төрки академиясе әгъзасы Айсылу Хөсәен кызы Садыйкова ярты гасырга якын гомерен татар фольклорын һәм әдәбиятын өйрәнүгә багышлый. А. Садыйкова үзенең хезмәтләрендә татар әдәбиятының фольклор белән бәйләнешен тикшереп, әдәбиятта халык иҗатыннан килгән тамырларны барлый. Ул беренчеләрдән булып татар халык иҗатында ислам идеологиясе, ислам дине йогынтысында формалашкан фольклор жанрларын, сюжет һәм образларны фәнни яктан тикшереп, аларны монографик юнәлештә яктырта. Шул ук вакытта А. Садыйкова татар

фольклорының төрле жанрларына караган үрнәкләрне тәрҗемә итеп, аларны рус телле укучыларга ирештерә.

Айсылу Хөсәен кызы 1946 елның 27 апрелендә Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Уразавыл авылында укытучылар гаиләсендә туа. Әтисе Хөсәен Азизбай улы Горький өлкәсендә татар мәктәпләре инспекторы, аннары Кучкай Пожары педагогика училищесы директоры, соңыннан Камка авылында мәктәп директоры була. Түбән Новгород өлкәсендә Хөсәен Башкуровның исемен әле дә зурлап искә алалар. Әнисе Зәйнәб Хәсән кызы шулай ук укытучы була. Ул тумышы белән Арча районыннан, зыялы муллалар нәселеннән. Әнисе ягыннан Айсылу Садыйкованың нәселе татар классик әдәбиятының күренекле вәкилләре – Фатих Әмирхан һәм Нәҗип Думавига барып тоташа. Шуңа күрә галимәнең беренчеләрдән булып ислам тәгълиматының халыкның рухи дөньясы белән бәйләнешен өйрәнә башлавы бер дә очраклы булмый.

Мәктәпне медаль белән тәмамлаганнан соң, Айсылу Садыйкова Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә, һәм аны тәмамлап, рус теле һәм әдәбияты белгече дипломы ала. Башта ул туган ягында рус теле укыта, Казанга кире әйләнеп кайткач, Татарстан архив идарәсенең Казан үзәк архивында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1977 елның февраленнән Айсылу Хөсәеновна үзенең тормышын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать (1997 елга кадәр Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих) институты белән бәйли – фәнни редактор, соңрак баш редактор булып эшли. 1983 елдан халык иҗаты бүлегенә күчерелә һәм бераздан «Г. Ибраһимов эстетикасында фольклор» дигән темага кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый.

Аның диссертациясе фәнгә тирән белемле, киң фикерле, җитлеккән галим килүен күрсәтә. Бу хезмәттә Г. Ибраһимовның иҗаты фольклор белән бәгланыш аша гына түгел, әдип иҗатының чор белән бәйләнеше, аның олы әдип булып җитешүенә рус классик әдипләренең йогынтысы да фәнни яктан ачыла. А. Садыйкованың татар һәм рус әдәбиятларын, фольклор теориясен яхшы белүе теманы төрле яктан тикшерүгә генә түгел, әдәбият һәм фольклор бәйләнешләрен алга таба өйрәнү өчен теоретик база булдырырга да ярдәм итә. 1995 елда «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» исемле беренче монографиясе дөнья күрә.

Кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң, ул ислам диненең татар халык иҗатына йогынтысын өйрәнә башлый, һәм бер-бер артлы диярлек галимәнең шушы өлкәдәге фәнни тикшеренүләре яктыртылган «Идеология ислама и татарское народное творчество» (2001), «Ислам һәм татар халык иҗаты» (2005) монографияләре басылып чыга.

Айсылу Садыйкова китапларында ислам мәдәнияте һәм идеологиясе тәэсирендә формалашып үсеп киткән жанрлар, сюжет, образ һәм мотивлар тикшерелә. Ул татар халкының мөнәҗәт жанрын

фәнни яктан өйрәнүгә зур игътибар бирә. Соңрак бу жанрны татар шагыйрьләре иҗатына нисбәттә ача, башка халыклар фольклоры белән типологик параллельләрне барлый. Айсылу Хөсәеновна мөнәҗәтләрне фәнни яктан өйрәнеп кенә калмый, аерым фәнни җыентыклар рәвешендә халыкка кайтару өчен дә зур тырышлык куя: «Мөнәҗәтләр» җыентыгы – 2000 елда, аның яңартылган басмасы 2010 да дөнья күрә, 2005 елда Татарстан китап нәшриятында рус һәм татар телләрендә «Мөнәҗәтләр – Мунаджаты» басмасы нәшер ителә. Рус телендәге текстларның фәнни академик тәрҗемәсен дә галимә үзе эшли. 2024 елда А. Садыйкова төзегән «Татар халык иҗаты. Мөнәҗәтләр» һәм «Татарское народное творчество. Мунаджаты» академик томнары басыла.

А. Садыйкованың «Ислам һәм татар халык иҗаты» монографиясендә татар фольклорының мөнәҗәтләр, мәкаль-әйтемнәр, легендалар, риваятьләр һәм мәзәкләр жанрлары «илаһият һәм кеше» аспектында тикшерелә. Галимә татар халкының этнографиясен, милли кыйммәтләрен яхшы белеп эш итә. Ул Коръәннән килгән персонажларның татар фольклорында чагылышын өйрәнә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллалаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган сюжетларны барлый. Татар халык иҗатында Мөхәммәд пәйгамбәр, бер яктан, җир кешесе буларак ачылса (тормыш юлы, никахы, хатыны Хәдичәгә, баласына, оныкларына мөнәсәбәте), икенче яктан, аның иманлы мөселманлыгы идеал буларак яктыртыла. Пәйгамбәрнең эпик биографиясенә фольклордан килгән могҗизалы мотивлар да өстәлә.

Монографияләрдә Искәндәр Зөлкарнәйн – Александр Македонский, легендар пәйгамбәр – мәңгелек юлчы Хызыр Ильяс, гүзәллек һәм тугрылык символы булып татар әдәбиятында үзенең урынын тапкан Йосыф галәйһиссәләм образлары да төрле яктан тикшерелә.

2014 елда нәшер ителгән «XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор» монографиясендә XII гасыр төрки-татар әдәбияты вәкиле Әхмәд Ясәви иҗатыннан башлап XX йөз башына кадәрге татар әдәбиятында дини фольклорның чагылышы тикшерелә. Автор Сөләйман Бакырганиның тәсаувыф идеяләрен, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында Коръәннән килгән мотивларның чагылышын, Котб, Харәзми, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Мәхмүд Болгари иҗатына дини мотивларның йогынтысын, Насретдин Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия» әсәрен һәм аның чыганакларын тикшерә. Татар әдәбияты дини традицияләре төрек шагыйре Юныс Әмрә иҗаты белән чагыштырма яссылыкта барлана. XV–XVI гасырлар әдәбиятында тәсаувыф идеяләре Өмми Камал һәм Сайяди иҗаты аша анализлана. Монографиядә Казан ханлыгы чоры әдәбияты һәм фольклорында дини мотивлар Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, А. Хафиз, М. Колый иҗатлары аша тикшерелә. Автор шушы ук мотивларның XVIII гасырда Габди, Габдессәлам, Исламкол, Г. Мөслимов, Т. Ялчыгол, Г. Утыз Имәни, Г. Кандалый иҗатларында дәвам итүен күрсәтә.

А. Садыйкова XX йөз башы татар әдипләре өчен «халык, милләт, дин» кыйммәтләренең аеруча актуаль булуын ассызыклый. Галимә бу китабын түбәндәге юллар белән тәмамлый: «Дөнья әдәбияты һәм халык иҗаты дин тарихының әдәби чагылышы булып үсеш ала. Христиан язучылар Библиядән, Инҗилдән этәргеч идеяләр алса, мөселман язучыларга Коръән илһам һәм сюжет, мотивлар бирә. Татар язучыларының күпгасырлык иҗаты моңа дәлил булып тора» (294 б.)

Алда әйтелгәнчә, Айсылу Хөсәен кызы тәрҗемәче һәм мөхәррир буларак та зур эш башкара. Ул «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» (1–2 т., 2008) җыентыклары автор һәм мөхәррирләренең берсе була; «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» («Татарское народное творчество: Сказки», т. 3, 2008), «Татар халык иҗаты: Табышмаклар» («Татарское народное творчество: Загадки», т. 4, 2008) җыентыкларын рус теленә тәрҗемә итә.

Айсылу Садыйкова үзенә фәнни алмаш әзерләүгә дә зур игътибар бирә. Аның җитәкчелегендә кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклана. Ул – аспирантлары, докторантларына фәндә генә түгел, тормышта да дөрес юл сайларга булышкан олы җанлы фидакяр зат.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Гыйлемҗанова Гөлназ Гыйлфан кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Закирова Ильсияр Гамиловна,***
*доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*ilzakirova@mail.ru*

***Гилемьянова Гульназ Гилфановна,***
*научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*golnaz-kazan@mail.ru*